ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

26 02 2024 г. № 180

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «2017 елның 1 сентябреннән Түбән Кама муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру турында» 2017 елның 25 июлендәге 476 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 2023 елның 10 июлендәге 293-ФЗ номерлы Федераль законы, 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы «Дәүләт социаль ярдәме турында»гы Федераль законы, Россия Федерациясенең 2023 нче елның 29 декабрендәге 2386 номерлы «Дәүләт информацион системасында «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» карарына таянып, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 25 июлендәге 476 номерлы карары белән расланган «2017 елның 1 сентябреннән Түбән Кама муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру турында» (алга таба – тәртип), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Тәртипнең 1.3 пунктын түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«3.1. Россия Федерациясенең 2023 нче елның 29 декабрендәге 2386 номерлы «Дәүләт информацион системасында «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» карары нигезендә, оператор билгеләгән форматларга яраклаштырып, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсенә (Гарифуллин А.Х.) бу карарда каралган ташлама бирү турындагы мәгълүматны урнаштыруны тәэмин итәргә.

2. 2017 елның 1 сентябреннән Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру турында «2017 елның 25 июлендәге 476 номерлы Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 сентябрендәге 607 номерлы Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карарының 2 пункты үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставында билгеләгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Интернет мәгълүматтелекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе башлыгы А.Х. Гарифуллинга йөкләргә.

Җитәкчесе Р.Ф. Булатов

ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044874